

Тормышта еш кына шулай була: бер тапкыр очрашкач, бер генә минутка да аерыласы килми. Кешене һәрвакыт беләсен кvк, карашларында, хисләрендә шулкадәр кvп уртаклык табыла. Беренче елмаю, беренче очрашу... беренче мәхәббәт бердәнбер гомерлек мәхәббәткә әйләнә.

Ринат белән Лариса Самойловлар тормышында нәкъ шулай була да. Искиткеч пар. Уйлап кына карагыз, бу нәфис ябык, модель кыяфәтле брюнетка - кvп балалы әни һәм әби инде! Аларнын бергә яшәvләренә 25 бәхетле ел vтте, комеш туйларын да август азагында vткәрделәр.  Эш шунда ки, язма геройларыбыз бер-берсе белән мәктәптән vк танышлар. Ларисанын ойләре тимер юл аша кvчеп урнашкан. Ринат һәр кич Ларисаны кvрергә дип шул юлны vтеп йоргән. Яшvсмерлек хисләре коннән-кон ныгыган һәм уку йортларын тәмамлагач, егет сойгәненә кул һәм йорәк тәкъдим итеп матур туй vткәргәннәр. Яратудан туган оч балага тәрбия биреп vстергәннәр. Башта яшь гаилә ата-аналары йортынын икенче яртысында яши башлаганнар. Әдиләләре дә шунда туган: бvген ул vзе әни (бала карау буенча декрет ялында). Кечкенә малайларына нибары оч ай. Кызлары, гаиләсе белән еш кына әти-әниләрендә кунакта булалар. Әйтеп китәргә кирәк дип уйлыйм. Тормышта кеше унайлылыкка, яхшылыкка омтыла. Шулай Самойловлар да, берничә ел элек, Ковылкино шәһәреннән Красная Пресня поселогына кvченеп яши башлыйлар. Бу якларда сокланырлык табигать, бик матур урыннар: нарат урманы, кvл, Мокша елгасы. Саф һава һәм алар янында якын кешеләре.

Самойловларнын оендә һәрвакыт тәмле, кvнелле һәм жылы. Уллары Дамир - Саранск Кооператив университетынын «таможня эше» белгечлеге буенча студент, Маратлары - Герой Гуреев исемендәге мәктәпнен жиденче сыйныфында укый. Малайлар әтиләре кебек спортчылар. Ринат - футбол буенча Мордовия Республикасы кубогы һәм суперкубогы иясе, футбол буенча Мордовия чемпионы. Дамирлары әтисе эзләре буенча

бара һәм ул да футбол буенча Мордовия Республикасы чемпионы булып тора. Ринат гомер буе футбол уйный. Бvген ул - «Спартак-Ковылкино» командасынын баш тренеры. Әгәр аларнын йортлары яныннан vтсән, еш кына юылган әчке киемнәр белән элгечләре тулган була. «Спартак» уенчыларынын кызыл футболкалары еpактан ук кvренә: тренер формаларны юарга оенә алган дигән сvз бу.
Әгәр Самойловлар эшкә алынсалар, аны топтән, намус белән алып баралар һәм ахырына кадәр житкерәләр. Авылда алар зур хужалык белән яшиләр: тавыклар, vрдәкләр һәм сарыклары бар. Остәлдәге ризыклар барысы да экологик чиста, табигый. Моннан тыш, Ринат аучылык белән мавыга, шуна кvрә рационда кош-корт та еш була. Ул эштә дә беренчеләр рәтендә, ин яхшылар, жаваплылар арасында. Гаилә башы кvптән тvгел генә жылылык чел-тәрләренен жылылык участогы башлыгы булган, ә бvген – «СервисСтрой»да. Тормышынын икенче яртысы – Ларисасы, «Елмаю-Улыбка» балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып тырышып эшли. Ул кvптән тvгел респуб-ликада инклюзив торкемнәр арасында ин яхшы няня булып танылды. 

Кvп балалы әни, беренче белеме буенча программист булса да, момкинлекләре чикләнгән сабыйларнын йорәкләренә бик тиз ачкыч таба. Ә бу бик жинел тvгеллеге барыбызга да мәгълум. Ул балаларны ярата һәм алар моны сизәләр, ярату белән жавап кайтаралар. Әлбәттә, эш гади тvгел. Бик кvп рухи коч ала, әмма шул ук вакытта энергия бирә торган хезмәт. Балалар - юаныч. Һәм алар тирә - якта булганда - бәхет кояштай елмая. Шулай итеп Ларисаларнын оендә дә, эшенендә дә - бәхет. Әлбәттә, бу барыннан да элек vзе яхшы кеше булудан тора. Анын әти-әниләре искиткеч игелекле, ярдәмчел, хөрмәтле кешеләр.
Ринатнын биография битләре катлаулы - ул бик яшьли әтисез кала. Самойлов Александр искиткеч яхшы кvнелле, ярдәмчел кеше булган, тик яшьли авырудан vлгән. Әнисе, Бабина Адилә Джарулла кызы Ковылкино шәһәрендә хормәтле хатын, хәрби шәһәрчектә кунакханә житәкчесе, кочле спортчы. Ринат Бабин Геннадий Васильевичны vзенен әтисе дип саный, чонки кечкенәдән ук ул аны тәрбияләгән, тормышка ойрәткән, дорес юлга салган. Геннадий Васильевич акыллы, хормәтле, яхшы кvнелле кеше булган, кызганычка каршы, озакка сузылган авырудан оч ел элек вафат булган. Бу кеше турындагы истәлек туганнарынын һәм якыннарынын йорәгендә мәнге сакланыр. Менә шулай Самойловлар мәхәббәттә, татулыкта яшиләр. Кvп эшлиләр, балалары һәм оныклары Диманы vстерешергә ярдәм итәләр: аларнын унышларына һәм казанышларына карап соенәләр. Бәхетле гаилә, киләчәкләре дә матур булсын.

**Наилә НАСЫРОВА**